**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен гамәлгә кую турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен гамәлгә кую турында» 2017 елның 26 декабрендәге ПУ-1169 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 13 октябрендәге ПУ-729 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты турында нигезләмәнең 6 пункты «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) тиешле рәвештә расланган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яисә) кәгазь чыганакта хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә;»;

б) Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) составында:

Комитет составыннан Р.И. Вәлиевны, Ә.А. Галиәкбәрованы, В.В. Парфеновны, Ю.П. Прохоровны, Р.С. Хафизовны, И.Р. Һидиятовны чыгарырга;

Комитет составына кертергә:

Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызын – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча);

Зарипов Айрат Ринат улын – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисен (килешү буенча);

Мерзон Елена Ефимовнаны – Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга институты (филиалы) директорын (килешү буенча);

Ризванов Ирек Асаф улын – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Соколова Светлана Вил кызын – Алабуга политехника көллияте директорын (килешү буенча);

Шәмсетдинов Айдар Илдар улын – инглиз теле тирәнтен өйрәнелә торган 165 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе директорын (килешү буенча);

Комитет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

В.Е. Козловның – «Педагогика, психология һәм социаль мәсьәләләр институты директоры (килешү буенча)»;

Д.М. Шакированың – «Татарстан Республикасының Мәгарифне үстерү институтының проект офисы әйдәүче фәнни хезмәткәре (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 04 март
№ ПУ-144